## ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын «Салагыш авыл җирлегенең» муниципаль берәмлеге Яморза торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**07.12.2020** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 12 сәгать 00 минутта «07» декабрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

"2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яморза торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум куләмендә узара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

-Яморза урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу).

-Яморза авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар, материаллар сатып алу һәм алыштыру;

-Яморза авылы территориясендә су насослары, сууткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен сантехник материаллар сатып алу;

-Яморза авылындагы зиратны койма белән әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гранданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 137 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны-70 кеше, бу 51% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенынндa 165 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салауш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яморза торак пунктында

гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салауш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яморза торак пункты территориясендэ, I төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум куләмендә узара салым чаралары җыюны кертүгә.

3.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Яморза урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу).

-Яморза авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар, материаллар сатып алу һәм алыштыру;

-Яморза авылы территориясендә су насослары, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен сантехник материаллар сатып алу;

-Яморза авылындагы зиратны койма белән әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.agryz.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.М. Фардутдинова